ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2020 Балык Бистәсе штп. №245пи

Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыра торган муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен хак түләү (бүләкләү) турында Нигезләмәне раслау хакында

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге “Тренерларга квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыра торган муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен хак түләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында” 1258 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында” Министрлар Кабинетының 2019 елның 22 октябрендәге 946 номерлы карарын үтәү йөзеннән КАРАР БИРӘМ:

1. Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыра торган муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен хак түләү (бүләкләү) турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча бүлеге” муниципаль казна учреждениесенә (Шакиров И. З.) “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче тренерларына югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен хак түләү (бүләкләү) турында” Килешүне ел саен төзүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 1 июнендәге “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Спорт мәктәбе” муниципаль бюджет учреждениесендә

эшли торган спорт резервын әзерләүче тренерларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен хак түләү (бүләкләү) турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 103пи номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының _____елның
___ ____________-дәге (-дагы)____
номерлы карары белән расланды

Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук спорт резервы әзерли торган муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче спортчы- инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләре өчен хак түләү (бүләкләү) турында

# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1. Әлеге Нигезләмә спортчы-инструкторларга, муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре тренерларына югары спорт казанышлары өчен, физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә югары сыйфатлы тренировка процессын тәэмин иткән яисә югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен хезмәт хакы фондының бүлеп бирелгән акчалары чикләрендә окладка (вазыйфаи окладка), хезмәт хакы ставкасына өстәмә түләүләр күләмен, шартларын һәм тәртибен тәгаенли (аныклый).

## II. ФИЗИК КУЛЬТУРА ҺӘМ СПОРТ МУНИЦИПАЛЬ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ СПОРТЧЫ-ИНСТРУКТОРЛАРЫНА ҺӘМ ТРЕНЕРЛАРЫНА ЮГАРЫ СПОРТ КАЗАНЫШЛАРЫ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ

1. Тренерларга, тренер-укытучыларга, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен хак түләү (бүләкләү) әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетында тиңдәшле финанс елына Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына каралган акчалар хисабына башкарыла.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында” 2018 елның 25 сентябрендәге 853 нче номерлы карары нигезендә югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук ярышларда алган нәтиҗәләр өчен хак түләү (бүләкләү) (алга таба – хак (бүләкләү)) билгеләнә:

дәүләт һәм муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүче дәүләт физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында” 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүче

дәүләт физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында”гы Нигезләмәнең 7 нче номерлы таблицасы нигезендә спорт резервы әзерләүче адаптив физик культура буенча тренерларга, укытучы-тренерларга (шул исәптән өлкәннәргә);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүче дәүләт физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында” 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүче дәүләт физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында”гы Нигезләмәнең 16 нчы номерлы таблицасы нигезендә спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга.

3. Хак (бүләкләү) күләме тәрбияләнүченең спорттагы нәтиҗәсе (күрсәткече) нигезендә тәгаенләнә һәм ярышларны оештыручы билгели торган судьялар комиссиясе тарафыннан бәяләнә, спортчы тарафыннан күрсәтелгән нәтиҗә мизгеленнән алып бер календарь ел дәвамында ярышлар беркетмәсен төзү юлы белән рәсмиләштерелә.

Әгәр бер календарь ел узгач спортчы ирешелгән күрсәткечләргә таянган булса, хезмәткә түләү күләме билгеләнә:

Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүче дәүләт һәм муниципаль физкультура-спорт оешмаларының адаптив физик культура буенча тренерларына, укытучы-тренерларына (шул исәптән өлкәннәргә) – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүче дәүләт физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында” 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүче дәүләт физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында”гы Нигезләмәнең 1 нче һәм 4 нче таблицалары нигезендә.

4. Югары нәтиҗәләре өчен ярышларда алган урынына ярашлы рәвештә югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен хак (бүләкләү) һәр дәрәҗәдәге ярышларда (спортчының сигез ярышыннан да артык түгел) спортчының шәхси һәм команда төрләрендә күрсәткән бер яхшы нәтиҗәсе өчен, әгәр андыйларда медаль комплектлары уйнатылса, процентлар суммасыннан чыгып билгеләнә.

Татарстан Республикасында спорт резервы әзерләүне гамәлгә ашыра торган дәүләт һәм муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче адаптив физик культура буенча тренерларга, укытучы-тренерларга (шул исәптән өлкәннәргә) югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга хаклар (бүләкләүләр) Россия Федерациясе Спорт министрлыгының төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чаралары һәм спорт чараларының Бердәм календарь планына (II өлеш) һәм Татарстан Республикасы спорт-массакүләм һәм физкультура чараларының (Татарстан Республикасы чемпионатлары өлешендә) агымдагы елга Календарь планына кертелгән ярышларда алынган урын нигезендә түләнә.

Нәтиҗәләре буенча адаптив физик культура буенча тренерларга, тренер-

укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә) югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен хак (бүләкләү) түләнә торган халыкара һәм бөтенроссия ярышлары исемлеге Россия Федерациясе Спорт министрлыгының төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чаралары һәм спорт чараларының Бердәм календарь планының II өлешендә тәгаенләнә.

5. Төп тренер белән бер үк вакытта эшләү шарты белән югары квалификацияле спортчы әзерләүгә өстәмә рәвештә җәлеп ителә торган адаптив физик культура буенча тренерларга, тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә) югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен спортчыларның тренировка эшенең атналык режимыннан эшләнгән вакыт күләменә пропорциональ рәвештә төп тренерларга булган кебек үк шартларда алган урыны нигезендә билгеләнә.

6. Рәсми халыкара һәм бөтенроссия ярышларында алган урын буенча ирешелгән нәтиҗәләр өчен спортчы-инструкторларның һәм спортчыларның хезмәте өчен түләү нормативы күләме спортчы-инструкторлар, спортчылар тарафыннан күрсәтелгән нәтиҗә мизгеленнән алып бер календарь ел дәвамында ярышлар беркетмәсе күчермәсе нигезендә билгеләнә.

7. Спортчы-инструкторларның һәм спортчыларның рәсми халыкара һәм бөтенроссия ярышларында ирешкән нәтиҗәләре өчен алган урынына ярашлы рәвештә хезмәтенә түләү нормативы һәр дәрәҗәдәге ярышларда (сигез ярыштан да артык түгел) спортчы-инструктор, спортчының программаның шәхси һәм команда төрләрендә күрсәткән бер яхшы нәтиҗәсе өчен, әгәр андыйларда медаль комплектлары уйнатылса, процентлар суммасыннан чыгып билгеләнә.

8. Адаптив физик культура тренерларына, тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә) хак түләү (бүләкләү) билгеләнә шул очракта, әгәр программа төрендә катнашучылар (парлар, төркемнәр, экипажлар, спортчылар командалары) саны түбәндәгечә булса:

кимендә 6 (инвалидлар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар шөгыльләнә торган спорт төрләреннән гайре);

кимендә 5 (инвалидлар һәм сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затлар шөгыльләнә торган спорт төрләре өчен).

Югары квалификацияле спортчы әзерләгән өчен адаптив физик культура тренерларына, тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә) хак түләү (бүләкләү) спортчы белән ярышларда нәтиҗә алганчыга кадәр кимендә ике ел эшләү шарты белән билгеләнә.

Адаптив физик культура буенча тренерларга, тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә) спорт әзерлеге программаларын тормышка ашыруда бригадалы эш ысулы белән бергә катнашучы югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен хак түләү (бүләкләү) директор боерыгы белән билгеләнә.

9. Хак (бүләкләү) күләме тренировка йөкләнеше күләменә бәйле түгел һәм ул билгеләнә:

Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче тренерларга, адаптив физик культура буенча тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә), спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга – Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы "Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында”гы карары белән расланган нормативлар нигезендә.

10. Хак (бүләкләү) Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карары нигезендә бирелә.

11. Тренерларга, физик культура буенча тренер-укытучыларга (шул исәптән өлкәннәргә), спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга хак (бүләкләү) фәкать төп эш урыны буенча гына билгеләнә (спорт-адаптив мәктәпләрдән гайре).